Дария САФИНА

Табигатьтән алдым моңнарны

Әлмәт, 2010 ел

Дария САФИНА

Табигатьтән алдым моңнарны

Шигырьләр

Әлмәт, 2010 ел

«Табигатьтән алдым моңнарны» исемле шигырьләр
җыентыгын нәшер итүдә һәм Боек Җиңүнең
65 еллыгы уңаеннан матди ярдәм күрсәткән
«Татнефть» ААҖнең генераль директоры
Шәфәгать Фахразый улы Тәхәветдиновка
һәм «Рухият» фондына зур рәхмәтемне белдерәм.

Бәяләмә

Дария Сафинаның җыентык итеп әзерләнгән шигырьләрен укып чыктым. Шигырьләр техник яктан төзек. Эчтәлек бар. Авторның тормыш тәҗрибәсе бай икәне, күпне кичергән һәм бик күзәтүчән кеше булуы сизелә. Халык вәкиле күзлегеннән карап, ул үзе яшәгән чорны сурәтли, бәяли, мактый яки тәнкыйтьли. Иҗатында төрле темалар яктыртыла: ил тарихы белән бәйләнгән язмышлар, үз буыны кичергән авырлыкларга сыкрау, гаделсезлекләргә ачыну, бүгенге уңышлар белән горурлану, туган җиргә мәхәббәт, якташлары батырлыгына соклану, әдәп-әхлак мәсьәләләре... Теле гади, халыкчан. Фикерен туры бәреп әйтә. Иң мөһиме, күңеле буш түгел, әйтер сүзе бар.

Ачлык елында туган, репрессия, сугыш афәтләрен кичергән, гомере буе илгә-халыкка хезмәт итеп яшәгән шигъри күңелле Дария апа Сафинага китабын чыгаруда матди ярдәм күрсәтү кирәктер дип саныйм.

Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА,
Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Үзем турында

Туган авылым минем, Әлкәем,
Ничек икән хәзер хәлкәең?
Шушында туып-үскән әткәем,
Килен булып төшкән әнкәем.

Мин, Сафина Дария Латыйп кызы (тумыштан Дәрия Латыйп кызы Латыйпова), 1921 елның 30 апрелендә Азнакай районы Әлкәй авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туганмын.

1924 елны әти бер төркем кешеләр белән яңа хуторга күчкән. Аңа «Кызыл Сукачы» исеме биргәннәр. Соңыннан ул (Таңай урыслары әйткәнчә, Шатер – шатра) Чатра исеме алган. Минем туган-үскән җирләрем табигатьнең бик матур бер почмагы. Ул чакта кеше аяк басмаган әкияти урманнар, төрле җиләкләргә бай аланнар, саф сулы салкын чишмәләр, инешләр... Урман-яланнарында каен җиләген, җир җиләген җыеп, саф һавасын сулап, урман моңын, кошлар сайравын тыңлап үстем мин. Үзем дә моңлы булдым...

Ямьле була, якты була
Чатраның җәйләре.
Кышын тәмле, мәтрүшкәле
Сөтле үлән чәйләре.

Минем әти-әни бик тырыш кешеләр иде. Ике абый, апам яшьтән үк әти-әнигә мал асрарга, икмәк чәчеп үстерергә, сугарга - барысына да ярдәм иттеләр.

Яңа урында әти урнашып, йорт төзеп тә бетерә алмады, 1930 елны кулак дип 5 елга утырттылар. Төзелеп беткән өйне (морҗа гына чыгармаган иде), безне куып чыгарып, колхоз идарәсе ясадылар. Малларны алдылар. Йорт эчендәге әйберләрне таладылар. Без урамда калдык. Кем кертсә, шунда торып йөрдек. Әнине дә төрмәгә утыртып, бер айдан кайтарттылар. Колхозга алмасалар да, әни ялланып гектары белән урак ура иде.

Әти 1934 елны котылып кайтты төньяк лагеренда булып. "Беломорканал" төзегәннәр. Колхозга алмасалар да, лесхозда эшләп йөрде. 1937 елның октябрендә НКВД хезмәткәрләре

әтине кулга алдылар. Аны өч ай Бөгелмә төрмәсендә яткырып, ун елга хөкем итеп, Идел утравына җибәргәннәр. Без әтидән читләштек, белешмәдек куркудан.

1988 елны әтиебезне аклагач, аның Свияжск төрмәсендә 1940 елның 3 ноябрендә вафат булганын белдек.

Минем яшьтән үк артистка-җырчы булырга теләгем бик зур булса да (сәләтем дә бар иде), язмыш мине Алабуга педагогия техникумына алып килде. Аны 1940 елны тәмамлап кайтып, Әлмәт районы мәктәпләрендә белем бирдем (Мәмәт, Кичүчат, Габдрахман, Мөгезле Елга, Бикәсаз, Иске Михайловка). Башта башлангыч сыйныфларда, аннан 5–7 нче сыйныфларда химия, биология, география укыттым. 1953 елны читтән торып Казан дәүләт укытучылар институтын тәмамладым (естественно-географический факультет).

1954 елны Әлмәт шәһәренә күчеп килдем. 5 нче рус мәктәбендә биология укыттым, китапханәсендә дә эшләдем.

1962 елны ШРМ-2гә күчеп, 5-8 нче сыйныфларда химия һәм биология укыттым.

1976 елны лаеклы ялга чыкканнан соң, еш кына җәмгать эшләрендә катнаштым. 1979 елны шәһәр ветераннар советында мәдәни-масса эшләре белән шөгыльләндем. Татар һәм рус хорларына нигез салдым. 25 ел дәвамында хорда җырладым һәм шигырь сөйләдем. Әйләнә-тирә мохитны саклау буенча үзем теләп инспектор булып йөрдем. 10 ел буе җирле радиодан шигырьләр сөйләдем, мәктәпләрдә, клубларда шигырьләр сөйләп, халык мәгарифе хезмәткәрләре арасында лауреат булдым. 15 ел "Әлмәт таңнары" газетасына мәкаләләр, шигырьләр яздым. Шәһәрнең яшеллегенә әһәмият бирдем. 1982 елны үзебезнең ишек алдына (Гафиятуллин, 10, 10а, 12, 12а) 155 төп агач утыртып, йортлар идарәсе, укучылар, яшәүчеләр ярдәме белән яшел зона булдырдык (урман үстердек), табигатьне ярату, шәһәрне яшелләндерү буенча приз - Мактау грамоталары алдым.

Халыкара "Филантроп" конкурсында катнашып номинант булдым (Габдулла Тукайның "Су анасы" шигырен рус телендә сәнгатьле итеп сөйләү буенча).

Мин тыл хезмәтчәне, ветеран укытучы.

Д.САФИНА (ЛАТЫЙПОВА).

Без күргәннәр

Сагынып кайттым туган авылга,
Калмаган шул нигез ташкае.
Свияжск төрмәсендә газап чиккән
Әткәсмнең газиз башкае.

Вөҗдансызлар төкреп, таптап китте
Әткәй икмәк чәчкән җирләрне.
Елый-елый сорап ялвардык без:
– Туздырмагыз безнең өйләрне!

Малыбызны килеп таладылар,
Этебезне кереп аттылар.
Әткәм-әнкәмне дә “кулак” диеп,
Бөгелмәгә илтеп яптылар.

Газиз әткәй, кичер инде, кичер,
Беләбез, гаебең юк иде.
Икмәк чәчеп, урып, мал асрадың,
Алты балаң шуңа тук иде.

Хәләл көчең белән өй җиткердең,
Салмадың син сарай-ташпулат.
Хәләл көчең белән көн күрсәң дә,
Ясадылар синнән зур “кулак”.

Бу дөньяда күпме михнәт кичтек,
Җәфа чиктек нахак-җәбердән.
Нәрсә әйтер иде икән әткәй,
Әгәр чыгып басса кабердән?

Болар гына әле бик аз булган,
Ясадылар "халык дошманы".
Авылдашлар куркып үтәделәр
Район КГБсы кушканын.

Шундый безнең тарих, күпне күрдек,
Сагышларны түгәм дәфтәргә.
Мондый газапларны кичерергә,
Ходай, насыйп итмә яшьләргә.

Һаман истә әле

(100 яшенә җитеп үлгән әнием –
Фәсхеттин кызы Зарифа хатирәсе)

Сугыштан соң ярлы илгә
Нык кирәк булган каучук.
Каучук зелпе тамырында,
Табар Зарифа карчык.

Лесник билгели йөкләмә:
Унбиш кило җыярга.
"Үтәмәсәң, синең башны
Беләм кая тыгарга".

Зарифа әби бик иртә
Китә урманга таба.
Зелпе куагын таба да,
Көнозын тамыр чаба.

Тамырны ваклап чаба да,
Төшерә каерысын.
Шундый авыр, вак эш бит бу,
Куллар гына чыдасын.

Бер көнне бик нык арыгач,
Ял итәргә утырса:
Хәйран кала матурлыкка,
Көн дә килә югыйсә.

Күке моңлана бер якта,
Чишмә челтерәп дәшә.
Яланында җир җиләге
Гөлләр белән серләшә.

Салкын чишмә суын эчеп,
Бер утырып хәл ала.
Улы хәбәрсез югалган,
Эчләрендә ут яна.

Кош сайравы, урман шавы
Тәмам аны уята.
Капчыгына кайры тыгып,
Караңгы төшкәч кайта.

Култык астында печәне,
Җилкәсендә урагы.
Алъяпкычта җир җиләге,
Бер кулында көрәге.

Төштә күрәм әниемне,
Яши һаман кайгырып...
Зелпе күрсәм, дога кылам,
Әниемне сагынып.

Әлкәй Чатрасы

Болганчык заман суында
Акты минем курчагым.
Ятим калдык, ойсез йөрдек –
Бәхетсез балачагым.

Яшел болын чәчәкләре
Булды минем кураем.
Идел утравында калды,
Әткәм – тоткын кониқаем.

Балачагым кыйпылчыгын
Алып китте давыллар.
Сагынып кайтсам, нигез юк,
Ярый әле авыл бар.

Бар иде бит авылымның
Гөрләп торган чаклары.
Басу тулы иген иде,
Ферма тулы атлары.

Бар иде бит мәчете дә,
Мәктәп, клуб, тегермән.
Буш урыннар кыргыйланган,
Дулап үскән әрекмән.

Уручы юк, чабучы юк,
Кая киткән бу халык?
Урман өскә авып тора,
Өйдә зәңгәр ягулык.

Яши әле өлкәннәрдән:
Өч ветеран – өч карчык.
Ходайга шөкер итәләр,
Пенсияләр бер янчык.

Кайтыгыз, яшьләр, кайтыгыз!
Дип чакыра Чатыра.
Урман шаулый, кошлар сайрый,
Таңнар иртә яктыра.

Туган яктан җилләр исә,
Җылы, якты нур булып,
Монда үткән шаулы яшьлек
Калды моңлы җыр булып.

Болганчык заман суында
Агып китте яулыгым.
Яулык түгел, саулык китте,
Килде шыксыз картлыгым.

Язма инде, дисез!

– Язма инде, яшең җиткән, – дисез,
Нигә кирәк сиңа язарга!
– Ничек язмыйм? Кар сулары күрсәм,
Күңел кире кайта язларга.

– Җәйләр җиткәч, язма инде, дисез, –
Йөр син су буенда, Зәйләрдә.
– Чәчәк күрсәм, күңел бөреләнә,
Ничек язмыйм инде җәйләрдә.

– Гомереңнең көзе җиткән, дисез,
Тутык кунган, дисез, йөзләргә.
– Сары яфрак күрсәм, сагыш баса,
Ничек язмыйм инде көзләрдә.

– Кышлар җиткәч, язмам инде, димен,
Ничек басыйм эчем пошканын.
– Ак кар күрсәм, күңел аклык тели,
Язам инде күңел кушканын.

Язгы моң

Әрни-әрни карыйм һәр таң саен
Күк болытлар йөзгән һавага.
Хәләлемне үлем тартып алды,
Ниләр табыйм икән дәвага?

Язлар алып килде зур югалту,
Кайгыларның килде карасы.
Йөрәк канаткаем иртә сынды,
Төзәлерме йөрәк ярасы?

Яз җилләре белән тибрәләләр
Су буенда соры камышлар.
Кар сулары белән агып китсен
Йөрәктәге әрнү, сагышлар.

И ходаем, бирче ярдәмеңне,
Әйләнмәсен йөрәк күмергә.
Рәхмәт әйтик ярты гасыр бергә
Яшәп үткән якты гомергә.

Кимсенмә

Сүзләр әйтсәләр кимсетеп,
Кызып китмә иң элек.
Булма үчле, бул син көчле,
Сабырлыкта өстенлек.

Кимсенсәң дә, хурлансаң да,
Сәлам бир ул кешегә.
Күңел күзе томаланган,
Рухы зәгыйфь көчсезгә.

Ашыгам

Хисләремне сүзгә җигеп,
Шигырь юллары тезәм.
Салкын карашлар өшетә,
Күңелем белән сизәм.

Язылмаган җырларым бар,
Үтәсе үрләрем бар.
Күңелем якты йолдыздай,
Ашыгам... вакытым тар.

Каләмгә үреләә кулым

Каләмгә үреләә кулым,
Язам фикерләремне...
Корым сибеп каралталар
Юган ак керләремне.

Үз фикеремне әйтергә,
Бар бит минем дә хакым.
Фикерләрем ошамаса,
Кичерер туган халкым.

Озын гомер агышында
Булгандыр ялгышлар да.
Ул ялгышлар ялгышмыни?
Ялгышлык язмышларда.

Ниләр күрәсем һәммәсе
Язылган язмышымда.
Уйларым да, моңнарым да
Чагыла сагышымда.

Улларым

Ике улым – ике канатым!
Икесен дә тигез яраттым.

Олысы: “Сәнгать – культура!” – ди,
Икенчесе: “Физкульт! Ура!” – ди.

Миңа бәхет: таза булсалар,
“Без исән!” дип, көлеп торсалар.

Моң

Без үскән чор – хотәр еллар иде,
Жыр, моңнарым күккә ашмады.
Күгәрекләр өскә калкып чыкты,
Энже-мәрҗәннәрне каплады.

Хәзер яшьләр сәхнәләрдә җырлый,
Тамак төбе белән кычкырып.
Тавышында моң булмагач йөрмә,
Тыңлаучының эчен пошырып.

Җырласаң син җырла сокланырлык,
Моңга төреп «Сакмар» буйларын.
Сәйдәш, Тукай, Рәшит, Илһам кебек
Карурманың, кәккүк моңнарын.

Моңны аны сатып алып булмый,
Моң бирелә безгә тумыштан.
Моң агыла затлы йөрәкләрдән,
Моң ярала тәүге сулыштан.

Азнакай уңганнары

Азнакаем – туган ягым,
Якын минем күңелгә.
Кешеләре дә бик эшчән,
Алыштырмыйм беркемгә.

Тау буенда җырлап ага
Бизәкле чишмәләре.
Азнакай кырларын бизи
Буровой сиртмәләре.

Әллә кайлардан күренә
Ямь-яшел урманнары.
Нефть чыгарып чыныккан
Азнакай уңганнары.

Мул уңышлар җыеп ала
Игенче-кырчылары.
Татарстанда беренче
Азнакай җырчылары.

Кичүчат

Риза Фәхретдин туган җир,
Дога иңгән туфракка.
Илаһи! сүзе халыкта,
Исеме бар тарихта.

Кешеләрең бик уңганнар,
Һәрбер эшкә яраклы.
Белем алырга сәләтле,
Белемлеләр – канатлы.

Өч дәрәҗә Дан орденлы
Батыр затларың да бар.
Сабантуйларын бизәгән
Очкын атларың да бар.

Бәхетле яшә, Кичүчат!
Яшәвеңә без бик шат.
Сиңа яшәргә көч биргән
Кара алтынга рәхмәт.

Татарстан нефте

Мин яшәгән авыл Чатра –
Нефть өстендә тора.
Су буенда качалкалар
Туктаусыз эшләп тора.

Кояш чыга алтын төсле,
Баеганда кызара.
Качалкалар җир астыннан
Кара алтын чыгара.

Кара алтын тиз әйләнә
Ак алтынлы суммага.
Чатра да өлешен кертксән
Өч миллиард тоннага.

Монда халык гомер буе
Суын ташып интеккән.
Хәзер су урамга килгән,
Өенә газын керткән.

Элек юл юк, машина юк,
Җәяү йөреп интектек.
Хәзер юллар ялтырап тора,
Бөтен җирдә тузсаклек.

Кара алтын чыгаручы
Шушы авыл егете.
Татарларның горурлыгы
Татарстанның нефте.

Ышаныч

Ышаныч – бик зур, саллы сүз,
Кайчак булмый аңлап та.
Тартып алып булмый аны
Җайлашып та, майлап та.

Ышаныч – димәк, ярамый
Алдашырга, алдарга.
Авырлыктан куркып эшне
Ярты юлда ташларга.

Ярамый алданырга да,
Сынарга-сыгылырга.
Ялган сүзләргә ышанып,
Төз юлда егылырга.

Ышанычның башы намус,
Гаделлек һәм төгәллек.
Ышанычны алу өчен
Игелек эшлә элек.

Ышаныч – ул җаваплылык,
Алдыңа куйган бурыч.
Язмышыңда рухи ныклык –
Тутыкмый торган корыч.

Горурланып йөрибез

Әлмәт авыл... Әлмәт бистә...
Әлмәт хәзер калабыз.
Әлмәтебезне яратып
Матур җырлар язабыз.

Иске Әлмәттән башланды
Кара алтын каласы.
Әлмәтебезне төзеде
Төрле милләт баласы.

Яшь буын үсә Әлмәттә,
Яшьләр акны кисеннәр.
Без Әлмәт кешеләре, дип,
Горурланып йөрсеннәр.

Урамнарда шаулап үсә
Ал чәчәкләр бәйләме.
Котлы булсын, ак Әлмәтем,
Илле еллык бәйрәмең!

Әлмәтебез бизәге

Борынгыдан Әлмәт җире
Игенчелек үзәге.
Зәй буенда Сабантуйлар –
Әлмәтебез бизәге.

Җем-җем кара туфрагында
Күкрәп үскән бодайлар.
Зәңгәр күктә уңыш теләп
Сайраганнар тургайлар.

Зәй буйлары әрәмәлек,
Дулкынлана сулары.
Сиртмәле насослар бизи
Чияле тау буйларын.

Нефть чыгарып чыныккан
Нефтьчеләр беләге.
Синдә чыккан кара алтын –
Җир-ананың бүләге.

Әлмәтебез, Әлмәтебез,
Кара алтын үзәге.
Алтын гөмбәзле мәчетең –
Әлмәтебез бизәге.

Гөлстан

Урманы күп, сулары бар,
Бу бит Әлмәт җирләре.
Бу җирләрдә күп түгелгән
Бабайларның тирләре.

Хәтерлим мин бу җирләрдә
Бодай уңган чакларны.
Кая барсам сагнып кайтам,
Шушы Әлмәт якларын.

Күл суында төзеделәр
Шарлавыклар – каскадлар.
Акыл белән эшкә аша
Зур планнар, максатлар.

Суларында көймә йөзә,
Ир акылы җир гизә.
Әкиятләрдәге кебек
Килеп чыкты могҗиза.

Яр буйлары төзекләнгән,
Гөлләр үскән берочтан.
Туган җиребез – Татарстан,
Әлмәтебез – Гөлстан.

Ветераннар үзәге

Әллә каян балкып тора,
Ак болыттай ак кораб.
Ветераннар көч-дәрт ала,
Шушы ак йортка карап.

Ак корабтай ап-ак йортка
Аклык теле күңелем.
Ак болыттай хисләр белән
Килдем әле мин бүген.

Егерме ел элек монда
Үзем башлап җырладым.
Яшьләй җыр сөюче булгач,
"Картайдым", – дип тормадым.

Эшли монда һөнәрчеләр:
Тегү-ямау, чәчтараш.
Өлкәннәргә дәва була
Җылы сүз, якты караш.

Шифаханәгә киләләр:
Бабай, әби, дәү әни.
Укол, массаж белән безне
Ак туташлар дәвалый.

Әлмәт җирлегендә йөзә,
Менә шундый корабль.
Ашханәсендә – аш әзер,
Клубында - ансамбль.

Җитәкчеләр бар да уңган,
Үзләре дә ветеран.
Игелекле эшләр өчен
Аларга зур ихтирам.

Каләмнәрегез талмасын

1999 елга

(журналистларны сәламләү)

“Әлмәт таңнары” аллана
Кояш чыгар алдыннан.
Туксанынчы елдан бирле
Һич төшермим кулымнан.

“Әлмәт таңнары”н сәламли
Зәйнең бодрә таллары.
Һәрбер йортка шатлык белән
Керсен “Әлмәт таңнары”.

Шушы газета җылыта
Безнең туңган җаннарны.
Яңа елдан тагын артсын
Аның тираж-саннары.

Милләт өчен бердәнбер ул
Безнең “Әлмәт таңнары”.
Һәрбер татар аны алсын,
Ерак китсен даннары.

Рәхмәтләремне әйтәмен
Журналистлар сафына.
Яңа елда зур уңышлар
Теләп сезгә – Сафина.

Үзәк парк

Җәйнең иң матур көнендә
Ачылды үзәк парк.
Яңа паркны күрергә
Бик күп җыелды халык.

Гөлбакчадай матур, күркәм,
Киңәйтелгән тар мәйдан.
Гүзәллекне күрү белән,
Бар халык калды хәйран.

Яктырткычлары яктырта
Паркның зәңгәр күген.
Эшле парк, гөрле парк,
Паркта бәйрәм бүген.

Син шушында килеп чык бер,
Ял итим дисәң әгәр.
Балаларга бик күңелле –
Шәһәр эчендә шәһәр.

Ял итәргә бик уңайлы,
Суларга саф һавасы.
Монда уен, монда җырлар,
Монда күңел дәвасы.

“Әлмәт таңнары” газетасы

Гашыйк “Әлмәт таңнары”на,
Укыйдыр Татарстан.
Әллә кайчан язылдым мин
Бернигә карамастан.

Хөрмәтле милләттәшләрем!
Сез дә уйлап карагыз.
“Әлмәт таңнары”н алмасак,
Без бит артта калабыз.

Ил-көн хәбәрләр языла
Шул “Әлмәт таңнары”нда.
Файдалы киңәшләр дә күп
Һәрбер кайткан санында.

Игелекле эш эшлибез,
“Әлмәт таңнары”н алып.
Милләтебезне күтәрик,
Йөрмик битараф калып.

Рухи игелек

Күрә белсәң җирдә матурлыкны,
Табигатьнең алтын төсләрен,
Рухи игелек алып куанырсың,
Аңлый белсәң йөрәк хисләрен.

Бал кортлары матур игелек эшли,
Үсемлекләр күптән билгеле.
Гөлләр чәчәк атып куандыра,
Нурландыра безнең күңелне.

Кеше булып туу әз әле ул,
Ходай кушкач адәм ярала.
Рухи игелек ит кешеләргә,
Игелекләр эшлә дөньяда.

Көзге бакчам

Көзге бакчам моңсуланды,
Яфраклары коелды.
Нахак сүзләр ишеткәчтен,
Йөрәккәем кыелды.

Язмыш мине айкап салды,
Төз юлымда аударды.
Кыек юлларга басмадым,
Үз юлыма кайталдым.

И гамьле язмышым минем,
Шигырьдә булса да кал.
Көзге бакчам моңсуланды,
Җимешләрен җыеп ал.

Үзгәрешләргә бер караш

Кызыл таллар сынмас иде,
Карга килеп кунмаса.
Үзгәрешләр булмас димә,
Доньья бит ул – куласа.

Үзгәрергә булыштылар
Куштаннар, ялагайлар.
Ике ара койрык болгап
Йөрүче алабайлар.

Илне тар-мар китерделәр
Ялагайлар, куштаннар.
Урлаштылар, баедылар,
Менә шулар – дошманнар.

Илләр имин булыр иде,
Аумакайлар булмаса.
Үзгәрешләр булмас иде,
Сатлык җаннар тумаса.

Бөек Җиңүнең 60 еллыгына һәм Әлмәт районының 75 еллыгына багышлана

Әлмәт чиге читән иде,
Кешеләр эшчән иде.
Егетләре җиткән иде,
Кызлары чибәр иде.

Сөлгеләрне чиккән идек
Сабантуйга бүләккә.
Сугыш! – дигән хәбәр керде,
Хәнҗәр булып йөрәккә.

Туган илне басып керде
Гитлер-фашист этләре.
Икенче көн яуга китте
Әлмәтнең егетләре.

Үлем хәбәре китерде
Өчпочмаклы хатлары.
Шуны сизеп боектылар
Хәтта колхоз атлары.

Фронт өчен, җиңү өчен
Яше-карты коч түкте.
Корал бирел, икмәк бирел,
Җиңүгә ярдәм итте.

Изге Ватан сугышында
Нык сугышты татарлар.
Әлмәт җирендә күп үсте
Йосыповтай батырлар.

Кырык бишнең май башында
Җиңү!!! – диеп сайрадылар
Сандугачлар, тургайлар.
Берлинда фашистны кыйнап,
Җиңеп кайтты геройлар.

Җиңү көне

Давыллар да, ташкыннар да
Юа алмас ул көнне –
Кырык бишнең май башында
Илгә килгән Җиңүне.

Озак бардык без бу көнгә
Зур югалтулар белән.
Еллар үтте, онытылмый
Сугышлар фашист белән.

Ил өстенә афәт килсә,
Шунда халык сынала.
Җиңү көне иң кадерле
Бәйрәм булып санала.

Еллар буе зур Җиңүне
Халык көтте түземсез.
Гасырлар да бәйрәм итәр,
Җиңү көне – үлемсез.

Тылда эшләүчеләргә

Авыр еллар безне тиз картайтты,
Китеп тора һәр көн яшьтәшләр.
Без бит теге өермәле чордан,
Онытмагыз шуны, иптәшләр!

Сугыш кырларында булмасак та,
Өермәләр керә төшләргә.
Икмәк өчен көрәш барды монда,
Туры килде көн-төн эшләргә.

Хатын-кызлар, картлар, малай-шалай
Сөрде, чәчте, җыйды икмәкне.
Эшелоннар китә торды төяп,
Фронт өчен барлык кирәкне.

Бала-чага ач-ялангач булды,
Үлем-хәсрәт күз-яшь коярлык.
Тылда эшләп җиңгән хатын-кызга
Әллә кайчан һәйкәл куярлык.

Солдат хатыннары каршысында
Башыгызны түбән игез!
Ирен искә алган Җиңү көнне
Ак сиреньнәр бүләк итегез!

1941 ел. Сугышка озату

Авыл яши, авыл эшли,
Үсте яшь егетләре.
Ватан өчен утка керде
Асылташ кебекләре.

Изге Ватан сугышына
Сөйгәнемне озаттым.
"Тиздән җиңеп кайтыр", – диеп,
Күңелемне юаттым.

Ул киткәчтен, әллә нигә,
Кара булды кигәнем.
Яу кырында ятып калды
Минем яшьләй сөйгәнем.

Бөтен ил белән күтәрдек,
Бу сугышның бәласен.
Шул китүдән күрәлмады
Ана газиз баласын.

Кемнәр генә татымады
Бөек сугыш казасын.
Әле һаман әрнеп сыкрый
Тән һәм йөрәк ярасы.

Ветераннар

Явыз Гитлер безнең илгә
Канлы сугышын ачкан.
Җиңү көннәре җиткәндә,
Үзе дөньядан качкан.

Безнең илнең егетләре
Геройларча сугышкан.
Туган илне саклау өчен –
Намусы шулай кушкан.

Геройларча сугышканнар
Газинурлар, Мусалар.
Алар исемен кушыгыз,
Ир балалар тусалар.

Окопларда да яттылар,
Сазлыкларда баттылар.
Ир-егетләр – каһарманнар,
Җиңү яулап кайттылар.

Орден-медальләр күкрәктә,
Аларга дан-ихтирам.
Сугышта да, хезмәттә дә
Алар булды ветеран.

Хәбәрсез югалганнар

Сугыш үткән киң далада
Үсә соры кылганнар.
– Кичерегез безне! – диләр,
Хәбәрсез югалганнар.

Сугыш кырыннан качмадык,
Уен уйнап ятмадык.
Танкларда янсак яндык,
Туган илне сатмадык.

Кай тарафларда ятасыз,
Шомлы-шикле сер булып.
Ватан өчен үлгәннәрнең
Даны кайтты җыр булып.

Тол хатын

Ниләр уйлыйсың, тол хатын,
Бу сугыш михнәтсенме?
Йә киләчәктә күрәчәк
Үзгәреш хикмәтенме?

Кемнәр әйткән, тол хатын, дип,
Әллә сугыш үземе?
Аналарны, балаларны
Сарды сугыш сөреме.

Һәлак булды! – дигән хәбәр,
Килеп керде өйләргә.
Ходай сабырлыклар биргән
Бу хәсрәткә түзәргә.

Сабанын да сез сөрдегез,
Печәнен дә чаптыгыз.
Утын төяп, салам төяп,
Чаналар да тарттыгыз.

Черек бәрәңгеләр ашап,
Балалар үстердегез.
Оныкларыгыз да җиткән,
Игелеген күрегез.

Сугыш уты кабынмасын,
Дөрләмәсен ялкыннар.
Беркайда да, беркайчан да
Тол калмасын хатыннар.

Бөек Ватан сугышы чорында җырлаган җырларым

("Тәзкирә" көенә)

Сәхрәләргә чыксаң, чыкма ялгыз,
Кызыл йолдыз булсын юлдашың.
Кызыл йолдыз булса, һай, юлдашың,
Мең дошманга торыр бер башың.

Кушымта:
Сикреп-сикреп ага кар суы,
Ник басылмый йөрәк ярсуы.

Сирәк кенә килгән хатларыңда
– Җиңү! – дигән сүзләр табыла.
Йолдызларга карап, сиңа атап,
Йөрәгемнән моңнар агыла.

* * *

(Тажи Гыйззәтнең “Бишбүләгем” драмасыннан “Партизаннар” җыры)

Һөҗүм иткән безгә явыз дошман
Болыннардан, судан, һавадан.
Таш стена булып күтәрелдек,
Бар авылдан, завод, каладан.

Кушымта:

Бишбүләгем, кайтсам, тарсынмассың,
Тиздән кайтам, кунак итәрсең.
Бездәй батыр егетләрең биреп,
Армиягә бүләк итәрсең.

Алты сугышчының берсе
Галимҗан Сафин

Алты малай, бер кыз үстек,
Мин булдым иң кечесе.
Олы абый безнең өчен
Арада иң көчлесе.

Җитми иде чабаталар,
Кием ертык-ямаулы.
Ишек төбенә тезелгән
Чабаталар санаулы.

Иртүк торып мин "элдерәм",
Мәктәпкәчә йөгерәм.
"Әзи" калган чабатасыз,
Мин куркып кайтып керәм.

Тугыз кашык җыелышып,
Утырабыз табынга.
Канлы сугыш бара икән
Илнең теге ягында.

Алты егет бер-бер артлы
Чыгып киттек сугышка.
Бишәү керде ут эченә,
Мин киттем көнчыгышка.

Алты улны озатуы
Җиңелме соң анага?
Улларыннан хатлар көтеп
Йөрәгеннән кан тама.

Ике абый һәлак булды,
Өчесе гарип кайтты.
Берсе сугыш газабыннан
Озак түшәктә ятты.

Япон-самурайга каршы
Без дә кердек сугышка.
Ай буенча кием салмый,
Алалмадык сулыш та.

Маньчжурия, Корея,
Камчатка да узылды.
Миңа да Ватан сугышы
Җиде елга сузылды.

Сәйдәш моңнары

Онытылмый, гел хәтердә
Тальян гармун чыңнары.
Яшьләй йөрәгемә сеңде
Сихри Сәйдәш моңнары.

Урманнарда җиләк җыйдым,
"Мәйсәрә"сен җырладым.
Урман мине кабатлады,
Кәккүкләр дә тыңлады.

Сәхнәм булды урман-кырлар,
Тамашачым – гөлләре.
"Гөлйөзем"нәр, "Зәңгәр шәл"ләр –
Болар Сәйдәш моңнары.

Чут-чут сайрый "Сандугач"ы
Ямьле "Кандыр" буенда.
"Бсз кабызган утлар сүнмәс"
"Асыльяр"лар туенда.

"Хуш, авылым, сау бул", – диеп,
"Батырҗан"нар киттеләр.
Яу кырында җиңәргә дә
Җырлар ярдәм иттеләр.

Җырлый-җырлый, гөрли-гөрли
Кызлар тула басалар.
Өмәләрдә вәгъдәләшеп,
Матур туйлар ясарлар.

"Их, күңелле өмәсе!" – дип,
Җырлагыз әле, яшьләр!
Моңнан һәйкәл койган зат ул,
Онытылмас Сәйдәшләр.

Картаймыйк әле

Матур яшьлек искә төшә
Гомерләр узган саен.
Картаймаска иде исәп,
Ничек табарга җаен?

Безнең яшьлекне көйдерде
Авыр сугыш еллары.
Үзгәрешләр алып килде
Авыр картлык юллары.

– Әни! – диеп килеп керсә,
Киленең белән улын,
Сузса сиңа йомшак кулын –
Шул синең бәхет юлың.

Әйтеп куйса газиз улың:
-Үзең кара! Үз җаең!
Тетрәндерсә ачы кайгың,
Сабырлык бир, Ходаем.

Табыйм дисәң яшәү җаен,
Тыныч булсын торагың.
Картаюның бар шатлыгы
Гаиләдә, мөгаен.

Ике толым

“Чәче озын – акыл кыска”,
Дию ялган сүз икән.
Акыллы кыз, чәчләре дә
Үкчәгә кадәр җиткән.

Ике толым – ике туган,
Пар толым тәнгәлләшә.
Ике толым, икс алтын –
Акыл, бәхет янәшә.

Сабыр холык, күркәм гадәт,
Күзләрендә балкый нур.
Чәче озын, акылы зур,
Исеме дә Асылнур.

“Табыгыз!” – дим

“Табыгыз, хатыннар, табыгыз!” – дим,
Курыкмагыз бала табудан.
Тик куркыгыз гөнаһ эшләүләрдән,
Тәмуг утларында янудан.

Бала табу горур, бөек эш ул,
Кешеләрдән калсын кешеләр.
Тусыннар акыллы, тәүфыйклылар,
Эшкуарлар, галим ишеләр.

Кыз балалар булса – илнең яме,
Ир балалар – илнең терәге.
Игелеккә чикләр куелмаган,
Игелекле булса йөрәге.

“Табыгыз, хатыннар, табыгыз!” – дим,
Курыкмагыз бала табудан.
Тик куркыгыз картлык көнгездә
Салкын ялгызлыкта калудан.

Кисәтү

Укып-белеп, күреп торам,
Дөньяда ниләр барын.
Әй, кешеләр, азынмагыз!
Саклагыз сез Җир шарын!

Кагылмагыз тышчасына,
Әйләнсен тыныч кына.
Атом-төш шартласа әгәр,
Күчәреннән ычкына.

Таламагыз җир байлыгын,
Уйла, адәм баласы.
Җир астында байлык бетсә,
Тагын кая барасы?

Табигатьне саклагыз сез,
Яшәргә теләсәгез!
Туфан сулары калыкса,
Упкынга тәгәрәрсез.

Айкамагыз боз диңгезен,
Тик ятсын салкын котып.
Гыйбадәт кылыйк, җәмәгать,
Яхшылыкка уй тотып.

Сикермәгез ай-кояшка,
Актармагыз галәмне...
Уйларым китте еракка,
Куеп торыйм каләмне.

Сандугач

(Вафирә Гыйззәтуллина истәлегенә)

Язлар җиткәч, бер сандугач
Сайрый алмас тирәктә.
Кайгы белән сагыш калды
Яраланган йөрәктә.

Җәйләр үтте, көзләр җитте,
Тиздән җитәр ак кышлар...
Мәңгелеккә китте инде,
Китте инде "Аккошлар".

Күккә ашты җырчы шаны
"Язгөлләр" арасыннан.
Әрнү калды йөрәкләрдә
Кайгының карасыннан.

Милләт, диеп, гомер буе
Түкте ул йөрәк көчен.
Оҗмахта булсын урыны
Аның моңнары өчен.

Чатра урманы

Яшел яфрак иле – урман,
Үзе ямьле, сөйкемле.
Барсаң ачык каршы ала,
Юмарт агай шикелле.

Урман эчләрендә йөри,
Поши микән, боланмы?
Урманга баш хуҗа бит ул,
Шул илдә тугангамы?

Яланнарда чиләк-чиләк
Җиләк җыйган чакларым.
Урман хәзинәсе бу дип,
Бик күп койдым какларын.

Затлы зелпе алкаларын,
Урман гөлләрен сөям.
Шау чәчәкле шомыртына,
“Яз бикәсе син”, диям.

Урман эчләрендә каен,
Яланнарда тирәкләр.
Галиҗәнап урман илен
Саклау минем теләкләр.

Кышкы урман

Урман ак толыбын кигән,
Җәйге гөлләр юк монда.
Ак күбектәй кар диңгезе,
Бигрәк матур саф дөнья.

Бар табигать тынып калган,
Ләкин алар тереләр.
Язлар житкәч уяныр лар
Агачларда бөреләр.

Әкрен генә җил сызгыра,
Кар өемен себерә.
Көрт астында җайлап кына
Тереклек яшп бирә.

Ак мамык шәл бөркәнгәннәр
Ак каеннар, юкәләр.
Кыш артыннан язлар килә,
Еллар шулай үтәләр.

Җырларга кушып җырлана
Яшел, карлы чыршылар.
Чыршыларга сәлам бирә
Үтеп барган юлчылар.

Тын урманны яңгыратып,
Тук-тук-тук килә тукран.
Кышкы урман матурлыгын
Сокланып карап торам.

Урманда яз

Язгы кояш елмайганда
Кышкы урман уянды.
Ак җәймәсен ыргытты да,
Җилпенеп сулап алды.

Исәнме, сөйкемле урман!
Мин сиңа килдем тагын.
Гөрләвекләр аккан чакта
Күрим, дип, урман язын.

Кышын килгән идем сиңа,
Карларың урап алды.
Ак юлларыңны таптадым,
Эзләрем шунда калды.

Җәен килермен мин тагын,
Яшел күлмәгең кигәч.
Кошлар бала чыгарганда,
Сайраганда сандугач.

Яшә, үс, сөекле урман!
Тамырларың тирәндер.
Җиләк-җимешләр мул бирең
Кешеләрне килэндер.

Керим әле урманнарга

Яратам бар табигатьне,
Яратам яшеллекне,
Сагынам шушы урманда
Җырлап үткән яшьлекне.

Урманнарга керү белән,
Сөяләм ак каенга.
Ак каеннар аклык өсти,
Бирешмәскә кайгыга.

“Мокамайлар” искә төшә,
Усакларны сыйпасам.
Сагышымны суырып ала,
Төпләрендә йокласам.

Кара урман әчләрендә
Чәчәк ата юкәләр.
Юкәләргә күз салмасам,
Алар миңа үпкәләр.

Үпкәләмәгез , юкәләр!
Сезне күрү бик рәхәт.
Баллы чәйләр, себеркеләр
Биргән өчен зур рәхмәт.

Сүз әйтмәгез имәннәргә,
Имән урманда түрә.
Имәннән сабырлык сора,
Сабырлык гомер бирә.

Иртә чәчкәләр

Табигатьтә бар тереклек
Көтә җылы язларны.
Яз җилләре бигрәк көчле –
“Ашый” көмеш карларны.

Агачлар да күк томанда,
Гел яшәү исәпләре.
Ярларына сыймый ага
Салкын боз кисәкләре.

Кар астыннан борын төртә
Беренче сары чәчәк.
Сары чәчәк – яз кояшы,
Күргәннәр сөенәчәк.

Шәрә урман эчләрендә
Кипмәс борын сазлары...
Бал чәчәге калкып чыга,
Ачып зәңгәр таҗларын.

Апрель инде саубуллаша,
Тама соңгы тамчылар.
Яз гөлләрен сәламләргә
Килегез, тальянчылар!



Соңгы чәчәкләр

Ромашкалар күптән инде
Чәчәк атып шиңделәр.
Чәчәк бәйрәмнәрс үтге,
Ярышларда җиңделәр.

Хуш исле горур пионнар
Матур чәчәк аттылар.
Сокланырлык букетларны
Базарларда саттылар.

Көз дә җитте салкынаеп,
Тәрәзәгә жил бәрә.
Агачлар да яфрак койган,
Куаклар да шәп-шәрә.

Күк йөзендә кара болыт,
Карлы яңгыр да ява.
Бөтен эшләрен тәгәлләп,
Көз атлый кышка таба.

Барыгыз, язга кадәрле
Ял итегез, гөлләрем.
Сезне юксынып кыш буе
Үтәр минем көннәрем.

Түтәлләргә сулар сибеп,
Өстегезгә ябармын.
Язлар җиткәч, сезне назлап,
Тамчы булып тамармын.

Чәчәкләрнең нинди юк,
Барысы да чибәрләр.
Җәй буена чиратлашып
Доньяга нур сибәрләр.

Җәйге яңгыр

Җәй: җылыта, кыздыра да,
Кайчак өшетеп куя.
Кайчак корылык китерә,
Кайчак яңгырын коя.

Кара болытлар кабарган,
Карангылана һава.
Күк күкери, яшен яшьни,
Яңгыр да коеп ява.

Ыңгыраша, шаулый урман,
Сайрамый сандугачлар.
Җил давыллый, яңгыр коя,
Чайкалалар агачлар.

Ядрәдәй яуган яңгырда
Рәхәт сыман поши га.
Поши йорты – ачык урман,
Аңа шулай ошый да.

Буразналарны тигезләп
Ага яңгыр сулары.
Корылыктан җәфа чиккән
Сугара басуларны.

Салават күпере чыккан
Ал кыекчасын бәйләп.
Монысы да ялгыш түгел,
Сулау очен бик әйбәт.

Яңгырдан соң кояш чыга,
Бар нәрсә тынычлана.
– Игенкәйләр уңсын! – диеп,
Бөтен халык куана.

Такмаклар

Кая бара бу дөньялар,
Ничек гомер итәргә?
Кызларыбыз шәрә йөри,
Инде нихәл итәргә?

Бот төбеннән кыска ыштан,
Авызында папирос.
Шәрә йөргән яшь кызларга
Гашыйк була карт урыс.

Эчкечелек, наркоманлык –
Нишләп йөри кыз бала?
Унөч яшьтән “гулять” итә,
Ни карый ата-ана?

Алтын алка, алтын йөзек,
Кулында алтын сәгать.
Алтын кию белән мине,
Алтындай булсын гадәт.

Бу дөньяда иң кадерле
Ике нәрсә бар, диләр:
Берсе – яшьлек белән сафлык,
Берсе – сөйгән яр, диләр.

Кайнар йөрәк

Көзнең була алтыны да,
Көзнең була салкыны.
Салкын көзләрне җылыта,
Кайнар йөрәк ялкыны.

Яшьлек бит ул – кайнар йөрәк,
Сөю утында яна.
Сөюнең дә чамасы бар,
Онытмасын кыз бала.

Кайнар йөрәк тиз суына,
Яшьлек үтә дә китә.
Ике йөрәк кавышканда
Саф булуга ни җитә.

Хәмер бәете

Улы эчеп кайтып керә,
Зур эш майтарган кебек.
Ана кеше куркып тора,
Йөрәген ярган кебек.

Урам тулы эчсез ирләр,
Бер сәбәпсез эчәләр.
Бик күбәйде бәйрәмнәр дә,
Туган көннәр, кичәләр.

Харап була яшь-яшь ирләр,
Бозылалар балалар.
Шул хәлләрне күреп торып,
Ут йоталар аналар.

Футбол уйнау ирләр өчен
Бик кызыклы бер уен.
Тоташ эчәргә сабышкан
Элеккеге чемпион.

Оттырсалар да эчәләр,
Отсалар да эчәләр.
Ипи алырга акча юк,
Бушап кала кесәләр.

И Ходаем, кодрәтең киң,
Акыл-зиһен бирсәнә.
Ил башлыгы, Сездән сорыйм,
"Сухой" закон кертсәнә.

Үгетләү

Язлар җитте, карлар эри:
Кардан ачылыр җирләр.
Шул җирләрне эшкәртергә,
Кайда сез, айнык ирләр?

Бездә шундый кара туфрак –
Мул игеннәр игәрлек.
Эшләмичә эчеп йөрү –
Бу соң нинди юләрлек?

Тез буының бушаганмы,
Кыек атлый аяклар.
Айнымыйча эчеп ятсаң,
Авылыңны кем яклар?

Гомер бакый айнык булып,
Иген иккән татарлар.
Айнымасаң, читләр килеп,
Авылыңны сатарлар.

Туры бас, туган, аякка,
Каран яшә як-якка.
Авылың күтәр аякка,
Калмыйм дисәң таякка.

Борынгыдан авылыңда,
Тырыш булган агайлар.
Шуңа күрә күкрәп уңган
Икмәк, карабодайлар.

Әй, егетләр, минем кебек
Кемнәр сезне үгетләр?
Җирдә уңыш алыр өчен
Кирәк айнык егетләр.

Мой город – Альметьевск

Альметьевск – любимый город,
Никому здесь не тесно.
Как и другие поэты,
О тебе слагаю песню.

Тут, на земле благодатной,
Растет богатый урожай.
«Визиткой» города стал
Сабантуй у реки Зай.

Нефтяники утром рано
Поехать на вахту встают.
Доброй вестью над головой,
Птички-жаворонки поют.

Альметьевск, у твоих детей
Каких только профессий нет!
«Черное золото» добывая,
Окрепли твои джигиты.

Альметьевск – любимый город,
Ты центр нефтяного края,
У храмов золотой купол
Блестит, взоры лаская.

Перевод М.Борханова.

* * *

Перестройка ускорила старение,
Годки нас потихоньку «покидают».
Да мы ведь сами из той эпохи бурной.
Вы, друзья мои, не забудьте это.

Хотя мы и не были на поле брани,
А ужасы войны в снах нас терзают.
Хлеб насущный мы тоже «с боем брали»,
Как было нам трудно – старики знают.

Жизнь в тылу тогда была на военный лад,
Хлеб выращивали солдатки, вдовы.
На фронт уходили эшелоны подряд,
Погрузив все нужное для Победы.

Читать письма собирались всей деревней,
Дети ходили голодны, без одежды.
От смертей, горя рекой слезы лились,
Все трудились, не теряя надежды.

Поклонитесь, люди, пред женами солдат!
Трудом они Победу приближали.
Где им, скажите Вы, памятники стоят?
Им памятники ставить не пора ли?

Перевод М.Борханова.

Гульстан

Красивы леса, озера и реки –
Это Альметьевский край.
Немало пота проливали предки,
Чтоб превратить землю в рай.

Я помню еще пору такую:
Тут было поле, росло жито.
Где бы не буду, затоскую,
Здесь вся жизнь прожита.

На бросовых землях построили
Водопады, озер каскады.
Ведь всегда рукам умелым
Мечту в жизнь воплощать надо.

В озерах паруса белеют,
Чайки сюда прилетели.
Умные руководители
Сказку в быль превратили.

Берега расцвели в роз.
Все радует сегодня глаз.
Родимый край – Татарстан,
Альметьевск мой – Гульстан.

Перевел с татарского
М.Борханов

2010 ел. Татар гимназиясе.
4 нче сыйныфта
Бөек Җиңүнең 65 еллыгында.

ЭЧТӘЛЕК

Бәяләмә (Рәмзия Габделхакова)..3
Үзем турында..4
Без күргәннәр...6
Һаман истә әле...8
Әлкәй Чатрасы..10
Язма инде, дисез!..12
Язгы моң..13
Кимсенмә..14
Ашыгам..15
Каләмгә үрелә кулым...16
Улларым...17
Моң...18
Азнакай уңганнары...19
Кичүчат...20
Татарстан нефте...21
Ышаныч..22
Горурланып йөрибез..23
Әлмәтебез бизәге..24
Гөлстан...25
Ветераннар үзәге..26
Каләмнәрегез талмасын..27
Үзәк парк...28
"Әлмәт таңнары" газетасы...29
Рухи игелек...30
Көзге бакчам..31
Үзгәрешләргә бер караш...32
Бөек Җиңүнең 60 еллыгына һәм Әлмәт районының
75 еллыгына багышлана..33
Җиңү көне...35

Тылда эшләүчеләргә..36
1941 ел. Сугышка озату..37
Ветераннар...38
Хәбәрсез югалганнар...39
Тол хатын..40
Бөек Ватан сугышы чорында
җырлаган җырларым...41
«Һөҗүм иткән безгә явыз дошман...» 42
Алты сугышчының берсе Галимҗан Сафин.................43
Сәйдәш моңнары...45
Картаймыйк әле..46
Ике толым...47
"Табыгыз!" – дим...48
Кисәтү..49
Сандугач..50
Чатра урманы..51
Кышкы урман...52
Урманда яз..53
Керим әле урманнарга...54
Иртә чәчкәләр...55
Соңгы чәчәкләр..56
Җәйге яңгыр..57
Такмаклар..58
Кайнар йөрәк...59
Хәмер бәсте...60
Үгетләү...61
Мой город – Альметьевск..62
«Перестройка ускорила старение...» 63
Гульстан..64

Дария САФИНА

Табигатьтән алдым моңнарны

Шигырьләр

Мөхәррир *Рәшит Бәшәров*

Чыгарылыш өчен җаваплы *Зөлхәбирә Әхмәтшина*

Компьютерда җыючы *Гөлфия Әхмәтханова*

Тышлыкны бизәүче
һәм верстка ясаучы *Айгөл Шәяхмәтова*

Подписано в печать 30.11.2010 г. Формат 60х84/16. Печать офсетная. Усл. печ. л. 4,5
Заказ № 2394. Тираж 100 экз. Отпечатано в ООО «Городская типография»
423450, РТ, г. Альметьевск, ул. Марджани, 82.